**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 17 ноябре № 1199

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яше тулган балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1154 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахка керү өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы 2021 елның 29 декабрендәге 1154 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гариза бирүченең формалаштырылган электрон формадагы запросының һәр юлын тутыру барышында, формат - логик тикшерү, органнар (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан, тутырылган электрон формадагы запросның хаталы юллары

ачыкланганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе, гариза бирүчегә мәгълүмати хәбәр итү юлы белән җиткерелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е. В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы М.Х. Хәбибуллова